| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.04.2020 г.Лениногорск № 528

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 08 августындагы 1109 номерлы карары белән расланган гражданга муниципаль торак фондының торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына социаль наем шартнамәсе буенча үзгәрешләр кертү турында

2020 елның 1 мартында кабул ителгән 35-ФЗ номерлы «Ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» гы Федераль законга таянып, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 08 августындагы 1109 номерлы карары белән расланган гражданга муниципаль торак фондының торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 3 подпункта «уллыкка (кызлыкка) алу турында карар» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 5 пунктчасының 3 абзацын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Лениногорские вести» рәсми публикатор-газетасында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнарны күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72